Рассмотрено и утверждено
на педсовете протокол № 1
МБДОУ “Староибрайкиский детский”
от 29.08.2014г.

Утверждено и введено в действие
приказом № от 29.08.2014
Заведующий МБДОУ
“Староибрайкинский детский сад”
_____________ М.М. Хасанова

# Рабочая программа музыкального руководителя муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения “Староибрайкинский детский сад ” на 2014-2015 учебный год

**Составила: музыкальный руководитель Сулейманова Р.В.**

# ЭЧТӘЛЕК


**АҢЛАТМА ЯЗУЫ**

**I. “МУЗЫКА” ӨЛКӘСЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ ТӨП МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ**

**II. БАШКА БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘЛӘРЕ БЕЛӘН БӘЙЛӘНЕШ**

**III. “МУЗЫКА” БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕНДӘ ТӘРБИЯЛӘҮ ҺӘМ БЕЛЕМ БИРҮ ПРОЦЕССЫН ПРОЕКТЛАУ**

**IV. “МУЗЫКА” БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕНДӘ 3-4 ЯШЬЛЕК БАЛАЛАРГА БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ ПСИХОЛОГО-ПЕДАГОГИК ЭШ ЭЧТӘЛЕГЕ**

1.3 ЯШЬТӘН АЛЫП 4 ЯШЬКӘЧӘ БАЛАЛАРНЫҢ ЯШЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

2. 3-4 ЯШЬЛЕК БАЛАЛАРГА МУЗЫКА ӨЛКӘСЕНДӘ КҮПКЫРЛЫ БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЕНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

3. МУЗЫКА ӨЛКӘСЕНДӘ ТӨП БУРЫЧЛАРНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУНЫҢ ЭШ ФОРМАСЫ

3.1. “ТЫҢЛАУ” БҮЛЕГЕ

3.2. “ҖЫРЛАУ” БҮЛЕГЕ

3.3. “МУЗЫКА РИТМЫНА ХӘРӘКӘТЛӘР”

**V. “МУЗЫКА” БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕНДӘ 4-5 ЯШЬЛЕК БАЛАЛАРГА БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ ПСИХОЛОГО-ПЕДАГОГИК ЭШ ЭЧТӘЛЕГЕ**

1. 4 ЯШЬТӘН АЛЫП 5 ЯШЬКӘЧӘ БАЛАЛАРНЫҢ ЯШЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

2. 3-4 ЯШЬЛЕК БАЛАЛАРГА МУЗЫКА ӨЛКӘСЕНДӘ КҮПКЫРЛЫ БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЕНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

3. МУЗЫКА ӨЛКӘСЕНДӘ ТӨП БУРЫЧЛАРНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУНЫҢ ЭШ ФОРМАСЫ

3.1. “ТЫҢЛАУ” БҮЛЕГЕ

3.2. “ҖЫРЛАУ” БҮЛЕГЕ

3.3.. “МУЗЫКА РИТМЫНА ХӘРӘКӘТЛӘР”

**VI. “МУЗЫКА” БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕНДӘ 5-6 ЯШЬЛЕК БАЛАЛАРГА БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ ПСИХОЛОГО-ПЕДАГОГИК ЭШ ЭЧТӘЛЕГЕ**

1.5 ЯШЬТӘН АЛЫП 6 ЯШЬКӘЧӘ БАЛАЛАРНЫҢ ЯШЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

2. 5-6 ЯШЬЛЕК БАЛАЛАРГА МУЗЫКА ӨЛКӘСЕНДӘ КҮПКЫРЛЫ БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЕНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

3. МУЗЫКА ӨЛКӘСЕНДӘ ТӨП БУРЫЧЛАРНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУНЫҢ ЭШ ФОРМАСЫ

3.1). “ТЫҢЛАУ” БҮЛЕГЕ

3.2. “ҖЫРЛАУ” БҮЛЕГЕ

**VII.** 3.3. “МУЗЫКА

**VIII. “МУЗЫКА” БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕНДӘ 6-7 ЯШЬЛЕК БАЛАЛАРГА БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ ПСИХОЛОГО-ПЕДАГОГИК ЭШ ЭЧТӘЛЕГЕ**

1.6 ЯШЬТӘН АЛЫП 7 ЯШЬКӘЧӘ БАЛАЛАРНЫҢ ЯШЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ
2. 6-76 ЯШЬЛЕК БАЛАЛАРГА МУЗЫКА ӨЛКӘСЕНДӘ КҮПКЫРЛЫ БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЕНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ
3. МУЗЫКА ӨЛКӘСЕНДӘ ТӨП БУРЫЧЛАРНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУНЫҢ ЭШ ФОРМАСЫ
3.1. “ТЫҢЛАУ” БҮЛЕГЕ
3.2. “ҖЫРЛАУ” БҮЛЕГЕ
3.3. “МУЗЫКА РИТМЫНА ХӘРӘКӘТЛӘР”

**IX. ПРОГРАММА ҮЗЛӘШТЕРҮНЕҢ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН ЙОМГАКЛАУ НӘТИҖӘЛӘРЕНӘ ИРЕШҮЕ БУЕНЧА МОНИТОРИНГ**
**X. “МУЗЫКА” БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕНДӘ БАЛАЛАРГА БЕЛЕМ БИРҮДӘ КУЛЛАНЫЛГАН ПРОГРАММАЛАР**

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Без тирән үзгәрешләр һәм үзгәртеп корулар чорында яшибез. Тәрбия-белем бирү эшендә бертөрлелектән арына барып, заман таләпләренә җавап бирә торган программалар, яңа технологияләр көннән-көн киңрәк кулланыла. Музыканың, башка сәнгать төрләренә караганда, кешегә тәэсир итү көче беренче урында тора. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның иң кечкенәләр төркемендә музыкаль эшчәнлекнең төп төрләре формалаша.

Мәктәпкәчә белем бирүдә музыка, нәниләрдә музыкаль-эстетик яктан матурлык, яхшылык сыйфатларын үстерүче буларак кабул ителә.

“Музыкаль тәрбия” өлкәсендә эш программасы балаларга музыкаль белем һәм тәрбия бирүдә төп нармотив документ булып тора. Аның төп идеясы – балаларда матурлык, кешелеклелек сыйфатлары тудыру, аларның иҗади сәләтләрен ачу. Эш программасы балаларның яшь үзенчәлекләренә һәм Дәүләт стандартларына туры килә һәм үз эченә түбәндәге бүлекләрне ала:

- тыңлау;
- җырлау;
- музыка ритмына хәрәкәтләр;

Эш программасының эчтәлеге: “Музыкаль” тәрбия өлкәсендә эш алып бару программасы эчтәлеге балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә.

Бурычлар:
- балаларда музыка культурасының төп сыйфатларын үстерү;
- музыка сәнгатенә карата дөрес караш тәрбияләү;
- балаларның эмоциональ-психологик үсешен тәэмин итү, сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту.

Музыкадан эш программасы вариатив комплекслы программага таянып, музыкаль эшчәнлекне, СанПин нәтиҗәләре буенча атнага ике тапкыр үткәрүне күз алдында тотып языла.

Балаларның музыкаль сәләтләре диагностика нәтиҗәләре буенча билгеләнә:
- музыкага карата эмоциональ җавап бирә белү;
- төгәл музукаль образлар тудыра белү;
- музыканың характерын сиземләү;
- җырлаганда сәнгатьле, сүзләрне аңлаешлы әйтеп җырлау;
- хәрәкәтләрне музыканың характерына туры китереп ритмлы, сыгылмалы, төгәл башкару; - төрле бию, җыр импровизацияләрен кулланып уен образларын тудыра белү;
- музыканың төрле өлкәләрендә активлык күрсәтү.

## 1. Музыка өлкәсендә төп бурычлар һәм максатлар.

**МАКСАТ: Балаларның музыкаль сәләтләрен үстерү, музыканы эмоциональ кабул итә белүне** түбәндәге бурычлар аша тормышка ашыру:

- ✓ музыкаль – сәнгать эшчәнлеген үстерү;
- ✓ музыка сәнгатенә тарту;
- ✓ балаларның музыкальлекләрен үстерү;

**«МУЗЫКА ТЫҢЛАУ»БҮЛЕГЕ**

-музыкаль әсәрләр белән таныштыру;
-музыкаль сәләтләрен, тыңлау культурасын үстерү;
-җырларның, инструменталь әсәрләрнең характерларын дөрес аера алуны үстерү;
-музыканы эмоциональ кабул итә белү сәләтен үстерү, музыкаль фикерләрен баету.

**<u>«ҖЫРЛАУ» БҮЛЕГЕ</u>**

-балаларда дөрес җырлау кагыйдәләрен формалаштыру;
-балаларны шөгыль вакытларында һәм шөгыльдән соңгы вакытларда да, аерым, күмәкләп, музыкаль инструментка кушылып һәм аннан башка гына да җырларга өйрәтү;
-музыкаль ишетү, тавыш югарылагын дөрес аеру сәләтен үстерү.

**<u>«МУЗЫКА РИТМЫНА ХӘРӘКӘТЛӘР»</u>**

-төрле хәрәкәтләр ясаганда, характерына һәм яңгырау көченә карап, ул хәрәкәтләрне үзгәртә белергә кунектерү;
-ике яки өч кисәктән торган әсәрнең характерын тоеп, хәрәкәтләрне мөстәкыль рәвештә төрләндерергә өйрәтү.
-балаларны биергә күнегүләр, уен образлары, түгәрәк уеннары аша өйрәтү;
-балаларның иҗади сәләтләрен үстерү.

## Оештырылган музыка эшчәнлеге өч өлештән тора.

### Кереш өлеш.

**Музыкаль – ритмик күнегүләр.**

**Максат** – баланы шөгыльгә катнашырга әзерләү, биюләрдә кулланылачак төп хәрәкәтләрне ясый белүләре өстендә эшләү.

## Төп өлеш.

**Музыка тыңлау.**

**Максат** – балаларда музыканы тыңларга омтылыш, төрле характердагы көйләрне тыңлаганда, аңа карата җавап хисләре тәрбияләү.

**Җырлау күнегүе, җырлау.**

**Максат** – балаларны көчәнмичә, сузып һәм җиңел, сәнгатьле, аһәңле итеп җырларга, сүзләрне ачык әйтеп, бердәм башлап бердәм бетереп җырларга өйрәтү.

## Тәмамлау өлеше.

Уен һәм бию.

## I. Башка төр белем бирү өлкәләре белән бәйләнеш.

| | |
|---|---|
| “Физик культура” | Музыкаль – ритмик эшчәнлек өчен балаларның физик үсешләрен ныгыту, музыкаль әсәрләрне төрле физик күнегүләр, ярышлар вакытында куллану. |
| “Сәламәтлек” | Балаларның физик һәм психик яктан сәламәтлекләрен ныгыту, сәламәт яшәү рәвешен кузалларга ярдәм итү, релаксация. |

| | |
|---|---|
| “Аралашу” | Музыка өлкәсендә өлкәннәр һәм балалар белән ирекле аралашуны үстерү; сөйләм телен үстерү, сүз байлыгын арттыру. |
| “Танып белү” | Балаларның музыка, музыкаль дөнья турындагы күзаллауларын киңәйтү. |
| “Социализация” | Музыкаль культура, сәнгатькә караш формалаштыру; уен эшчәнлеген үстерү, гаиләгә, тормышка. Дөньяга карата патриотик караш тәрбияләү. |
| “Иҗади сәнгать” | Балалар сәнгатен үстерү, сәнгатьнең төрле төрләрен берләштерү, музыкаль әсәрләрне “Музыка” белем бирү өлкәсен тулыландыру максаты өчен куллану. |
| “Әдәби әсәр уку” | Әдәби әсәр укыганда аның тәэсир итү көчен арттыру өчен музыкаль әсәрләр куллану. |
| “Куркынычсызлык” | Музыкаль эшчәнлектә куркынычсызлык кагыйдәләрен куллану. |

## III.“Музыка” белем бирү өлкәсендә 3-4 яшьлек балаларга белем бирүнең психолого- педагогик эш эчтәлеге

### 3.1. ЯШЬТӘН АЛЫП 4 ЯШЬКӘЧӘ БАЛАЛАРНЫҢ ЯШЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Бу яшьтәге балаларга музыкаль тәрбия бирүнең төп эчтәлеге - балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис – тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтү. Бу яшьтә балаларда музыканы “ишетә” белү сәләте ачыла башлый. Бала әсәргә карата эмоциональ җавап бирә башлый. Күңелле көй ишетсә шатлана, ә моңлы, сагышлы көйне тыңлаганда балаларда теләктәшлек, кызгану хисләре уяна. Баштарак бала музыкаль әсәрне бербөтен итеп кабул итә. Тора-бара ул әсәрдәге бизәлешләрне, интонацияләрне ишетә башлый.

Җырлау сәләте акрынлап камилләшә бара. Тавыш ярылары әле формалашып бетмәгән, тавыш мускуллары җитәрлек үсеш алмаганлыктан тавышлары бик акрын гына чыга. Шуның өчен балалар өчен җырлар бик кыска һәм гади булырга тиеш. Балалар һәрвакыттагыча уен формасында оештырылган өйрәтүләрне яраталар.

Балаларны музыкага тарту ритмик хәрәкәтләр аркылы да тормышка ашырыла. Төрле кызыктыргыч күнегүләр, музыкаль уеннар, биюләр, түгәрәк уеннары балаларга музыканы тоярга, яратырга өйрәнергә мөмкинлек тудыралар.

Музыкаль тәрбия бирүдә эш программасының үзенчәлекле ягы шунда – ул барлык сәнгать төрләрен ( сөйләм, җырлау, бию, уен) берләштерә.
Балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килерлек итеп, тиешле дәрәҗәдә сайланылган репертуар балаларны ардырмый, киресенчә аларга шөгыль вакытларында үзләрен актив тотарга ярдәм итә. Бөтен бер шөгыль берләшү формасында үтә. Балалар музыкаль белем бирү процессында актив катнашучылар булалар.

.

**3.2. 3-4 ЯШЬЛЕК БАЛАЛАРГА МУЗЫКА ӨЛКӘСЕНДӘ КҮПКЫРЛЫ БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЕНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ**

**МАКСАТ: Балаларның музыкаль сәләтләрен үстерү, музыканы эмоциональ кабул итә белүне** түбәндәге бурычлар аша тормышка ашыру:

- ✓ музыкаль – сәнгать эшчәнлеген үстерү;
- ✓ музыка сәнгатенә тарту;
- ✓ балаларның музыкальлекләрен үстерү;

**«МУЗЫКА ТЫҢЛАУ»БҮЛЕГЕ**

-музыкага эмоциональ мөнәсәбәт тәрбияләү;
-музыкаль сәләтләрен, тыңлау культурасын үстерү;
-музыканың характерын (күңелле, дәртле, тыныч) аңлау, аңа җавап хисләре тәрбияләү;
-музыкаль хәтерләрен үстерү, тыңлаган җырларны һәм пьесаларны ны эмоциональ кабул итә белү сәләтен үстерү, музыкаль фикерләрен баету.

**«ҖЫРЛАУ» БҮЛЕГЕ**

-балаларда дөрес җырлау кагыйдәләрен формалаштыру;

-балаларны шөгыль вакытларында һәм шөгыльдән соңгы вакытларда да, аерым, күмәкләп, музыкаль инструментка кушылып һәм аннан башка гына да җырларга өйрәтү;

- барлык балалар белән бер темпта, сүзләрне ачык һәм аңлаешлы әйтеп, көйнең характерына туры китереп (күңелле, сузынкы, ягымлы) җырларга өйрәтү.

**«МУЗЫКА РИТМЫНА ХӘРӘКӘТЛӘР»**

- ике кисәкле музыкага һәм яңгырау көченә (акрын-көчле) карап хәрәкәт итәргә өйрәтү;
- музыканың башына һәм ахырына игътибар итү (хәрәкәтләрне мөстәкыйль рәвештә башлау һәм тәмамалау);
- балаларны биергә күнегүләр, уен образлары, түгәрәк уеннары аша өйрәтү;
- балаларның иҗади сәләтләрен үстерү.

**Музыка тәрбиясенең максаты**:

Музыкага карата эмоциональ мөнәсәбәт тәрбияләү; өч музыкаль жанр белән (җыр, бию, марш) таныштыру; музыкаль хәтерне үстерү (тыңлаган җырларны һәм пьесаларны танып белү күнекмәләрен формалаштыру); көйнең характерын (күңелле, күңелсез, салмак, дәртле һ.б.) аңлау, аңа җавап хисләре тәрбияләү.

**Тыңлау**

Балаларны музыкаль әсәрне ахырга кадәр тыңларга күнектерү, әсәрнең эчтәлеген, характерын аңларга, җырда кем яисә нәрсә турында җырлаганны аңлап тыңларга өйрәтү. Музыкаль әсәрнең яңгырау көчен (көчле, тыныч) аера белү сәләтләрен үстерү.

**Җырлау**

Балаларны музыкаль инструментка кушылып дәртле, күңелле, моңлы, сузынкы җырларны ягымлы, итеп, көчәнмичә (ре – (ми) –ля (си) диапазонында) җырларга өйрәтү. Бер темпта, бер-берсеннән калмыйча һәм алга да китмичә, сүзләрне ачык әйтеп җырларга өйрәтү.

**Музыка ритмына хәрәкәтләр**

Балаларны ике өлештән торган музыкага кушылып, төрле хәрәкәтләр ясаганда, характерына һәм яңгырау көченә (тын гына, көчле) карап, ул хәрәкәтләрне үзгәртә белергә күнектерү. Төрле җәнлек кыяфәтләрен күрсәткән хәрәкәтләр(“аю килә”, “песи килә” һ.б.) ясарга өйрәтү. Музыканың башын һәм ахырын дөрес билгеләп, мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итәргә, маршка аерым-аерым һәм күмәкләп атларга өйрәтү. Салмак һәм дәртле музыканың характерына туры китереп, уртача һәм кызу темпта атларга өйрәтү.

Балаларга парлап әйләнү, аякларны чиратлаштырып тыпырдату һәм бер аяк белән тыпырдатып бию, төрле әйберләр (кульяулык, тасмалар һ. б.) белән хәрәкәтләр ясау, ярымчүгәләү, аяк очларында атлап йөрү кебек бию хәрәкәтләре өйрәтү.

Шөгыльләр СанПин нормаларына туры китереп атнага ике тапкыр 15әр минутлык итеп үткәрелә.

**Ел ахырына бала:**

- Музыкаль әсәрне ахырга кадәр тыңлый белә, таныш җырларны, музыканың характерын аера белә.
- Музыкаль яңгырашның үзгәрүен (тын гына, көчле) сиземли ала.
- Бер темпта, бер – берсеннән калмыйча һәм алга да китмичә, сүзләрне ачык әйтеп җырлый.
- Парлап әйләнү, аякларны чиратлаштырып тыпырдату, төрле әйберләр тотып (кульяулык, тасмалар һ. б.) бии белә.

### 3.3. МУЗЫКА ӨЛКӘСЕНДӘ ТӨП БУРЫЧЛАРНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУНЫҢ ЭШ ФОРМАСЫ

### 3.1. БҮЛЕК. *«ТЫҢЛАУ»*

| Эш формасы | | | |
|---|---|---|---|
| Режим моменты | Педагогның бала белән бергә эшләве | Баланың мөстәкыйль эше | Гаилә белән бергә эшләү |
| **Балаларны берләштерү формасы** | | | |
| Аерым<br>Төркем белән | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым | Аерым<br>Кечерәк төркем | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым |
| Музыканы куллану:<br>-иртәнге гимнастикада һәм физкультура шөгыльләрендә;<br>- музыка шөгыльләрендә;<br>- башка шөгыльләрдә; (тирә-якны танып белү, сөйләм телен үстерү, рәсем)<br>-җылы көннәрне урамда<br>- сюжетлы-рольле уеннарда;<br>- көндезге йокы алдыннан;<br>- йокыдан уянганда;<br>- бәйрәмнәр һәм күңел ачу кичәләрендә. | • Шөгыльләр;<br>• Бәйрәмнәр һәм күңел ачулар;<br>• Музыка көндәлек тормышта:<br>-башка шөгыльләрдә;<br>-төркемнәрдә музыкаль әсәрләр тыңлау;<br>-ял вакытында (өйрәнгән җырларны кабатлау);<br>-балалар уеннары<br>-рәсемнәр, балалар китапларыннан иллюстрацияләр карау. | • Музыка эшчәнлеге белән аерым шөгыльләнү өчен төркемнәрдә музыка почмагы булдыру: музыкаль инструментлар, уенчыклар, костюм элементлары, атрибутлар булдыру. Төрле тавыштагы музыкаль уенчыклар белән экспериментлар үткәрү.<br>• Үзлекләреннән уен формасында “бәйрәмнәр”, “концертлар” куюю. | • Ата-аналар өчен белешмәлекләр булдыру<br>• Ата-аналар җыелышлары<br>• Аерым әңгәмә<br>• Ата-аналар белән берлектә бәйрәмнәр, бәйгеләр, күңел ачу кичәләре үткәрү, аларга әзерләнү.<br>• Театральләштерелгән кичәләр, оештыру.<br>• Ачык ишекләр көне үткәрү.<br>• Ата-аналар өчен ширмалар булдыру.<br>• Гаиләдә бәйрәмнәр үткәрүгә ярдәм итү. |

## 3.2. Бүлек «ЖЫРЛАУ»

| Эш формасы | | | |
|---|---|---|---|
| Режим моменты | Педагогның бала белән бергә эшләве | Баланың мөстәкыйль эше | Гаилә белән бергә эшләү |
| **Балаларны берләштерү формасы** | | | |
| Аерым<br>Төркем белән | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым | Аерым<br>Кечерәк төркем | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым |
| • Жырны куллану:<br>- музыка шөгыльләрендә;<br>- юыну вакытларында;<br>- башка төр шөгыльләрдә;<br>- жылы көннәрне урамда<br>- сюжетлы-рольле уеннарда;<br>-театральләшкән бәйрәмнәрдә;<br>- бәйрәмнәр һәм күңел ачу кичәләрендә. | • Шөгыльләр<br>• Бәйрәмнәр һәм күңел ачулар<br>• Музыка көндәлек тормышта:<br>-башка шөгыльләрдә;<br>-төркемнәрдә;<br>-ял вакытында (өйрәнгән жырларны кабатлау);<br>- уеннар, түгәрәк уеннары вакытында;<br>-рәсемнәр, балалар китапларыннан иллюстрацияләр карау. | • Музыка эшчәнлеге белән аерым шөгыльләнү өчен төркемнәрдә музыка почмагы булдыру: музыкаль инструментлар, уенчыклар, костюм элементлары, атрибутлар булдыру. Тавышлар белән экспериментлар үткәрү.<br>• Дидактик уеннар. | • Ата-аналар өчен белешмәлекләр булдыру<br>• Ата-аналар жыелышлары<br>• Аерым әңгәмә<br>• Ата-аналар белән берлектә бәйрәмнәр, бәйгеләр, күңел ачу кичәләре үткәрү, аларга әзерләнү.<br>• Театральләштерелгән кичәләр, тавышлы оркестрлар оештыру.<br>• Ачык ишекләр көне үткәрү.<br>• Ата-аналар өчен ширмалар булдыру.<br>• Гаиләдә бәйрәмнәр үткәрүгә ярдәм итү |

## *1.3.* Бүлек *«МУЗЫКА РИТМЫНА ХӘРӘКӘТЛӘР»*

| **Эш формасы** | | | |
|---|---|---|---|
| Режим моменты | Педагогның бала белән бергә эшләве | Баланың мөстәкыйль эше | Гаилә белән бергә эшләү |
| **Балаларны берләштерү формасы** | | | |
| Аерым<br>Төркем белән | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым | Аерым<br>Кечерәк төркем | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым |
| • Музыка ритмына хәрәкәтләрне куллану:<br>- музыка шөгыльләрендә;<br>- иртәнге гимнастикада һәм физкультура шөгыльләрендә;<br>- башка төр шөгыльләрдә;<br>- сюжетлы-рольле уеннарда;<br>-театральләшкән бәйрәмнәрдә;<br>- бәйрәмнәр һәм күңел ачу кичәләрендә. | • Шөгыльләр<br>• Бәйрәмнәр һәм күңел ачулар<br>• Музыка ритмына хәрәкәтләр көндәлек тормышта:<br>-башка шөгыльләрдә;<br>-төркемнәрдә;<br>-ял вакытында (өйрәнгән хәрәкәтләрне кабатлау);<br>- уеннар, түгәрәк уеннары вакытында;<br>-туган көн бәйрәмнәре. | • Музыка эшчәнлеге белән аерым шөгыльләнү өчен төркемнәрдә музыка почмагы булдыру: музыкаль инструментлар, уенчыклар, костюм элементлары, атрибутлар булдыру. Тавышлар белән экспериментлар үткәрү.<br>• Төрле бию көйләренә үзлекләреннән хәрәкәтләр уйлап табуга этәрү. | • Ата-аналар өчен белешмәлекләр булдыру<br>• Ата-аналар җыелышлары<br>• Аерым әңгәмә<br>• Ата-аналар белән берлектә бәйрәмнәр, бәйгеләр, күңел ачу кичәләре үткәрү, аларга әзерләнү.<br>• Театральләштерелгән кичәләр, тавышлы оркестрлар оештыру.<br>• Ачык ишекләр көне үткәрү.<br>• Ата-аналар өчен ширмалар булдыру.<br>• Гаиләдә бәйрәмнәр үткәрүгә ярдәм итү |

## 4. “Музыка” белем бирү өлкәсендә 4-5 яшьлек балаларга белем бирүнең психлого- педагогик эш эчтәлеге.

### 4.1. 4 ЯШЬТӘН АЛЫП 5 ЯШЬКӘЧӘ БАЛАЛАРНЫҢ ЯШЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Уртанчы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның уен эшчәнлегендә рольле мөнәсәбәтләр барлыкка килә. Бу яшьтәге балалар кабул ителгән рольдән үзләрен аера башлыйлар. Уен процессында рольләр үзгәрергә мөмкин. Алар үзләре өчен түгел, ә уенны мәгънәле итү өчен уйный башлыйлар. Уендагы һәм чынбарлыктагы мөнәсәбәтләр аерымлана.

Уртанчылар төркемендә балаларның хәрәкәт координациясе үзгәрә башлый. Җитезлекләре, төгәллекләре арта. Кечкенәләр төркемнәрендәге балалардан аермалы буларак алар гәүдәләрен төз тотып йөри алалар. Шуның өчен уртанчылар төркеме балалары төрле каршылыклар аркылы җиңел генә атлап чыга алалар. Туп белән уйнау хәрәкәтләре дә катлаулана.

Дүрт яшь ярымда балалар инде күпкә үсеш алган булалар. Алар төрле предметларны биеклекләре, төсләре буенча группаларга җыялар. Хәтерләре дә күпкә арта. Алар берьюлы җиде-сигез предмет исемен истә калдыра алалар. Берничә куплетлы шигырьләрне бик тиз өйрәнәләр.

Күз алдына китерү, уйлап чыгару сәләте үсә. Балалар зур булмаган әкиятләр уйлап чыгарып сөйли алалар. Игътибарлыклары да күзгә күренеп арта. Катлаулы булмаган биремнәрне бик җиңел эшли алалар.

Балаларның сөйләм телләрендә дә алга китеш күзәтелә. Авазлар әйтелеше һәм дикция яхшыра. Сөйләм балаларның активлыкларын үстерә. Алар төрле җәнлек, хайван тавышлары чыгаралар. Теге яки бу персонажның сөйләмен интонация белән аерып күрсәтә алалар. Сөйләмнең ритмик төзелеше, рифмасы игътибарга лаек. Сөйләмнең грамматик ягы үсеш ала. Балалар грамматик кагыйдәләр нигезендә яңа сүзләр уйлап чыгару белән мавыгалар.

Бала белән олыларның аралашу эчтәлеге үзгәрә. Ул бала эләккән конкрент ситуациядән читкә тайпыла. Танып белү мотивы алга чыга. Аралашу вакытында алган мәгълүматлар бик үк аңлашылып бетмәсәләр дә, балада кызыксыну уяталар.

Бала өлкәннәрнең үзен ихтирам итүләрен тели, мактау сүзе аның өчен бик зур әһәмияткә ия була бара. Бу баланың артык үпкәләүчән булуына китерә. Шелтә, кисәтүләргә тискәре мөнәсәбәт туа. Артык үпкәләүчәнлек бу яшьнең феномены булып тора.

Яшьтәшләре белән бала сайлап кына аралаша башлый. Ул кайбер иптәшләренә өстенлек бирә. Уен вакытында даими партнерлар барлыкка килә. Төркемдә лидерлар аерылып чыга башлый. Көндәшлек, ярышу барлыкка килә. Ярышу үзеңне башкалар белән чагыштыру өчен әһәмиятле. Бу үз чиратында *Мин* образының үсешенә китерә.

Бу яшьнең төп казанышлары уен эшчәнлеге үсү; рольле һәм тормышчан үзара бәйләнешләр барлыкка килү; сурәтләү эшчәнлеге үсү; үзең уйлап конструкцияләү; планлаштыру, зиһенгә алу сәләте камилләшү, образлы, хыялый фикерләү, танып белүдә мин-минлек (минеке генә дөрес дигән позиция); хәтер, игътибар, сөйләм, дәлилли белү сәләте үсү, олыларның хөрмәтенә ихтыяҗ формалашу, үпкәләүчәнлек, көндәшлек, ярышу кебек сыйфатлар барлыкка килү. *Мин* образының үсүе белән характерлана.

## 4.2 4-5 ЯШЬЛЕК БАЛАЛАРГА МУЗЫКА ӨЛКӘСЕНДӘ КҮПКЫРЛЫ БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЕНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

Уртанчылар төркеме балалары инде күп кенә музыкаль белем алган, алар тыңлау, җырлау, музыка ритмына хәрәкәтләр, уеннар өлкәләренә бик актив катнаша башлыйлар.
Шөгыльләр белем бирүнең төп формасы булып тора. Балаларга бирелүче биремнәр дә катлаулана. Шөгыльләр атнага ике тапкыр, эш программасындагы бурычларга нигезләнеп, 20 минутлык итеп үткәрелә.

Бу яшьтәге балаларда музыкаль әсәрне тыңлаганда, җырлаганда, эмоциональ халәт барлыкка килә. Шуның өчен бу яшьтәге балаларда музыканы ярату хисләре, аны тыңлау теләге тәрбияләүне дәвам итәргә, музыка өлкәсендәге белемнәрен үстерүгә булышлык итәргә кирәк.

Балаларга музыкаль белем бирү өч өлештән тора.

**1.Кереш өлеш.** Музыкаль-ритмик күнегүләр.

Максат - баланы шөгыльгә катнашырга әзерләү, биюләрдә кулланылачак төп хәрәкәтләрне ясый белүләре өстендә эшләү.

1. **Төп өлеш**. Музыка тыңлау.

Максат – музыканы тыңлый белү күнекмәләрен формалаштыру: әсәрне бүленмичә һәм бүлдермичә ахырына кадәр игътибар белән тыңларга өйрәтү
Җырлау. Максат – балаларны сәнгатьле итеп җырларга өйрәтү, сузып, хәрәкәтләр ясап, башкалар белән килештереп җырлый алу күнекмәләрен формалаштыру.
Төп өлешкә шулай ук балаларның хәтерләрен, сиземләү сәләтләрен үстерүче, аваз югарылыгын ишетергә, музыка ритмын сиземләргә өйрәтүче төрле музыкаль дидактик уеннар да кертелә.

2. **Тәмамлау өлеше.** Уеннар һәм биюләр.

Максат — балаларда музыка характерына туры килүче ритмлы хәрәкәтләнү күнекмәләрен формалаштыру, шатлык хисләре, катнашасы килү теләге уяту.

**Ел ахырына бала :**

- Музыкаль әсәрне игътибар белән тыңлый, аның характерын сиземли. Үз фикерен сүз, рәсем, хәрәкәтләр аша җиткерә белә.
- Җырларны көеннән таный белә.
- Авазларның югарылыгын аера (секста-септима эчендә).
- Сузынкы итеп, сүзләрне аңлаешлы итеп әйтеп җырлый; җырны бергә башлап бергә тәмамлый.
- Бию хәрәкәтләрен башкару: ярым чүгәләү, сикереп атлау, берәрләп һәм парлап әйләнү, сыгылмалы йөреш .
- Предметлар белән күнегүләр башкару (уенчыклар, тасмалар, кубиклар һ.б.).
- Җырларны, түгәрәк уеннарны сәхнәләштерә белү (тәрбияче белән берлектә).

## 4.3 МУЗЫКА ӨЛКӘСЕНДӘ ТӨП БУРЫЧЛАРНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУНЫҢ ЭШ ФОРМАСЫ

### 4.3.1. Бүлек. *«ТЫҢЛАУ»*

| Эш формасы | | | |
|---|---|---|---|
| Режим моменты | Педагогның бала белән бергә эшләве | Баланың мөстәкыйль эше | Гаилә белән бергә эшләү |
| **Балаларны берләштерү формасы** | | | |
| Аерым<br>Төркем белән | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым | Аерым<br>Кечерәк төркем | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым |
| Музыканы куллану: | • Шөгыльләр | • Музыка эшчәнлеге белән | • Ата-аналар өчен белешмәлекләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| -иртәнге гимнастикада һәм физкультура шөгыльләрендә;<br>- музыка шөгыльләрендә;<br>- башка шөгыльләрдә; (тирә-якны танып белү, сөйләм телен үстерү, рәсем)<br>-җылы көннәрне урамда<br>- сюжетлы-рольле уеннарда;<br>- кцндезге йокы алдыннан;<br>- йокыдан уянганда;<br>- бәйрәмнәр һәм күңел ачу кичәләрендә. | • Бәйрәмнәр һәм күңел ачулар<br>• Музыка көндәлек тормышта:<br>-башка шөгыльләрдә<br>-төркемнәрдә музыкаль әсәрләр тыңлау<br>-ял вакытында (өйрәнгән җырларны кабатлау)<br>-балалар өчен әкиятләрдән музыкаль өзекләр тыңлау;<br>-рәсемнәр, балалар китапларыннан иллюстрацияләр карау;<br>- композиторлар портретларын карау. | аерым шөгыльләнү өчен төркемнәрдә музыка почмагы булдыру: музыкаль инструментлар, уенчыклар, костюм элементлары, атрибутлар булдыру.<br>Тавышлар белән экспериментлар үткәрү.<br>Оркестрлар төзеп уйнау. | булдыру<br>• Ата-аналар җыелышлары<br>• Аерым әңгәмә<br>• Ата-аналар белән берлектә бәйрәмнәр, бәйгеләр, күңел ачу кичәләре үткәрү, аларга әзерләнү.<br>• Театральләштерелгән кичәләр, тавышлы оркестрлар оештыру.<br>• Ачык ишекләр көне үткәрү.<br>• Ата-аналар өчен ширмалар булдыру.<br>• Гаиләдә бәйрәмнәр үткәрүгә ярдәм итү.<br>• Театрлар, концерлар карау. |

## 4.3.2.Бүлек *«ЖЫРЛАУ»*

| **Эш формасы** | | | |
|---|---|---|---|
| Режим моменты | Педагогның бала белән бергә эшләве | Баланың мөстәкыйль эше | Гаилә белән бергә эшләү |
| **Балаларны берләштерү формасы** | | | |
| Аерым | Төркем белән | Аерым | Төркем белән |

| Төркем белән | Кечерәк төркем<br>Аерым | Кечерәк төркем | Кечерәк төркем<br>Аерым |
|---|---|---|---|
| • Җырны куллану:<br>- музыка шөгыльләрендә;<br>- юыну вакытларында;<br>- башка төр шөгыльләрдә;<br>- җылы көннәрне урамда<br>- сюжетлы-рольле уеннарда;<br>-театральләшкән бәйрәмнәрдә;<br>- бәйрәмнәр һәм күңел ачу кичәләрендә. | • Шөгыльләр<br>• Бәйрәмнәр һәм күңел ачулар<br>• Музыка көндәлек тормышта:<br>-башка шөгыльләрдә;<br>-төркемнәрдә;<br>-ял вакытында (өйрәнгән җырларны кабатлау);<br>- уеннар, түгәрәк уеннары вакытында;<br>-рәсемнәр, балалар китапларыннан иллюстрацияләр караганда таныш булган җырларны бергәләп җырлау. | • Музыка эшчәнлеге белән аерым шөгыльләнү өчен төркемнәрдә музыка почмагы булдыру: музыкаль инструментлар, уенчыклар, костюм элементлары, атрибутлар булдыру. Тавышлар белән экспериментлар үткәрү.<br>• Дидактик уеннар уйнаганда таныш булган җырларны җырлау.<br>• Курчаклар өчен “концерт” әзерләү (курчаклар булып таныш җырларны җырлау). | • Ата-аналар өчен белешмәлекләр булдыру<br>• Ата-аналар җыелышлары<br>• Аерым әңгәмә<br>• Ата-аналар белән берлектә бәйрәмнәр, бәйгеләр, күңел ачу кичәләре үткәрү, аларга әзерләнү.<br>• Театральләштерелгән кичәләр, оештыру.<br>• Ачык ишекләр көне үткәрү.<br>• Ата-аналар өчен ширмалар булдыру.<br>• Гаиләдә бәйрәмнәр үткәрүгә ярдәм итү<br>• Өйрәнгән җырларны өйдә эти-әниләр белән бергә җырлау. |

### 4.3.3 Бүлек *«МУЗЫКА РИТМЫНА ХӘРӘКӘТЛӘР»*

| **Эш формасы** | | | |
|---|---|---|---|
| Режим моменты | Педагогның бала белән бергә эшләве | Баланың мөстәкыйль эше | Гаилә белән бергә эшләү |
| **Балаларны берләштерү формасы** | | | |

| Аерым<br>Төркем белән | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым | Аерым<br>Кечерәк төркем | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым |
|---|---|---|---|
| • Музыка ритмына хәрәкәтләрне куллану:<br>- музыка шөгыльләрендә;<br>- иртәнге гимнастикада һәм физкультура шөгыльләрендә;<br>- башка төр шөгыльләрдә;<br>- сюжетлы-рольле уеннарда;<br>-театральләшкән бәйрәмнәрдә;<br>- бәйрәмнәр һәм күңел ачу кичәләрендә. | • Шөгыльләр<br>• Бәйрәмнәр һәм күңел ачулар<br>• Музыка ритмына хәрәкәтләр көндәлек тормышта:<br>-башка шөгыльләрдә;<br>-төркемнәрдә;<br>-ял вакытында (өйрәнгән хәрәкәтләрне кабатлау);<br>- уеннар, түгәрәк уеннары вакытында;<br>-туган көн бәйрәмнәре. | • Музыка эшчәнлеге белән аерым шөгыльләнү өчен төркемнәрдә музыка почмагы булдыру: музыкаль инструментлар, уенчыклар, костюм элементлары, атрибутлар булдыру. Тавышлар белән экспериментлар үткәрү.<br>• Төрле бию көйләренә үзлекләреннән хәрәкәтләр уйлап табуга этәрү.<br>• Курчаклар белән бәйрәм үткәрү, төрле хайваннар, җәнлекләрне сурәтләгән хәрәкәтләр ясау. | • Ата-аналар өчен белешмәлекләр булдыру<br>• Ата-аналар җыелышлары<br>• Аерым әңгәмә<br>• Ата-аналар белән берлектә бәйрәмнәр, бәйгеләр, күңел ачу кичәләре үткәрү, аларга әзерләнү.<br>• Театральләштерелгән кичәләр, оештыру.<br>• Ачык ишекләр көне үткәрү.<br>• Ата-аналар өчен ширмалар булдыру.<br>• Гаиләдә бәйрәмнәр үткәрүгә ярдәм итү.<br>• Гаиләдә бию көйләренә фонотека булдыруга ярдәм итү. |

## V. “Музыка” белем бирү өлкәсендә 5-6 яшьлек балаларга белем бирүнең психолого – педагогик эш эчтәлеге.

### 5.1. 5 яшьтән алып 6 яшькәчә балаларның яшь үзенчәлекләре.

Бу яшьтәге балалар уен башыннан рольләрне бүлеп, шушы рольгә кереп уен ахырына кадәр уйный алалар. Уен барышында үзара мөнәсәбәт эчтәлеге буенча да, интонациясе буенча да рольгә туры килгән аралашу белән үрелеп бара. Балаларның чынлыкта аралашкан сөйләм теле, роль сөйләм теленнән аерылып тора. Балалар социаль мөнәсәбәтләрне аңлый башлыйлар, кайсыдыр роль башкалар белән чагыштырганда алар өчен якынрак була. Рольләр бүлгәндә төрле конфликтлар чыгарга мөмкин. Уен тирәлеге оешканлыгы күзәтелә, “үзәк” һәм “периферия” аерылып чыга. (“Больница” уенында үзәк – врач кабинеты, “Парихмахерская” уенында – чәч кисү залы – үзәк, көтү залы – периферия). Уеннарда балаларның эш гамәлләре күпкырлыга әйләнә. Балаларның сынлы сәнгать эшчәнлекләре үсә. Бу вакыт балаларның иң актив рәсем ясау чоры. Ел дәвамында балалар 2000 артыграк рәсем ясарга сәләтле. Эчтәлекләре буенча рәсемнәр бик төрле: китап һәм каралган фильмнарга иллюстрацияләр, көндәлек тәэсирләр, күзаллаган вакыйгалар. Гадәттә рәсемнәр төрле обьектларның схематик сурәтләрен чагылдыралар, ләкин композицияләренең оригинальлекләре белән аерылып торалар. Кеше рәсеме пропорциональрәк һәм була башлый. Рәсемгә карап кешенең җенесе һәм эмоциональ хәләте турында төгәл әйтеп була. Төсләрне, формаларны, зурлыкларны, предметлар төзелешен аңлап кабул итүләре камилләшә. Алар төп төсләрне генә түгел, барлык төсләрне дә, овал, өчпочмак, турыпочмаклык формаларын да әйтә башлыйлар. Объектларның зурлыкларын кабул итәләр, 10 га кадәр төрле предметларны үсә бару һәм кими бару тәртибендә бик җиңел төзиләр.

Шулай да балалар тирә - юньдәге объектларның торышын анализлаганда авырлыклар кичерәләр. Кабул итү балаларда төрле авырлыклар тудыра, бигрәк тә берьюлы берничә, шул ук вакытта капма-каршы билгеләрне исәпкә аласы булса. Образлы фикерләү мәктәпкәчә яшьтә үсүен дәвам итә. Балалар билгеләре буенча  предметларны группаларга туплый алалар. Психологлар тикшеренүләреннән күрсәкәнчә, мәктәпкәчә өлкән төркем балаларының күз аллаулары оригиналь һәм эзлекле хикәяләр төзергә мөмкинлек бирә. Ләкин күз аллаулары аны үстерү өчен махсус эш алып барганда гына үсеш ала. Сөйләм  үсеше дәвам итә, бигрәк тә аваз ягы. Балалар сызгырулы, сонор һәм чыжылдаучы авазларны дөрес әйтә башлыйлар. Фонематик ишетү сәләте, сәнгатьле сөйләм теле көндәлек тормышта, сюжетлы рольле уеннарда  үсә.

Баланың аңга алуы катлаулы формалы объектларны анализлый алуыннан чыгып характерлана;  гомумиләштерү, күз аллау, ирекле игътибар сәләте, сөйләме, “Мин”  үсеш ала.

## 5.2. 5-6 яшьлек балаларга музыка өлкәсендә күпкырлы

**белем бирү эшенең эчтәлеге.**

Оештырылган эшчәнлек төп белем бирү формасы булып тора. Өлкәннәр төркеменә бирелгән эшләр уен һәм күңел ачу элементларыннан торса да зур игътибарлык, сабырлык, фикерне туплый алуны сорый. Оештырылган эшчәнлек 25 минуттан атнага 2 тапкыр үткәрелә.

**“Тыңлау”.**

Музыкага мәхәббәт тәрбияләү, кызыксыну хисләрен, нәфасәти тойгыларын үстерүне дәвам итү. Татарстан Республикасы Дәүләт гимны көе белән таныштыру, горурлык хисләре уяту. Музыкаль әсәрләрнең жанр төрләрен (марш, бию, җыр) аера белергә өйрәтү. Таныш әсәрләрдән өзекләр тыңлап (кереш өлеш. Тәмамлау өлеше, музыкаль фраза), музыкаль хәтерләрен камилләштерү. Төрле музыка уен коралларын яңгырашы буенча аера белү күнекмәләрен камилләштерү.

**“Җырлау”.**

Җырлау күнекмәләрен формалаштыру, җырлар алдыннан. Музыкаль фразалар арасында тын алырга, сүзләрне ачык әйтергә. Җырны бердәм башлап, бердәм тәмамларга , табигый тавыш белән җырларга өйрәтү. Җырларны музыка уен коралларына кушылып яисә музыка уен коралыннан башка мөстәкыйль рәвештә ялгыз башкара алу сәләтен үстерү. Яраткан җырларыннан җыр фонды оештыру һәм җыр белән кызыксынуларын, җырлау теләкләрен үстерү.

**“Музыка ритмына хәрәкәтләр”.**

Ритмны тою сәләтен үстерү. Музыканың характерын, эмоциональ эчтәлеген хәрәкәтләр аша күрсәтә белү: тирә – юньдә ирекле ориентлашу, мөстәкыйль рәвештә темпны үзгәртү. Бию хәрәкәтләрен башкара алу күнекмәләрен, бию иҗатын формалаштыру. Җырны сәхнәләштерү күнекмәләрен үстерүне дәвам итү. Рус халык биюләре, түгәрәк уеннары, шулай ук башка халыкларның биюләре белән таныштыру.

**Ел ахырына бала**:

- Музыкаль әсәрләрнең жанр төрләрен (марш, бию, җыр) аера белү, әсәрләрне көеннән, кереш өлешеннән таный белү.
-тавышны көчәнмичә, җиңел тавыш белән, бердәм башлап җырлый һәм тәмамлый белү.

-музыканың динамик төсмерләренә, характерына туры китереп, ритмик рәвештә хәрәкәт итә, мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтләрне үзгәртә белү.
- мөстәкыйль рәвештә җырларның, түгәрәк уеннарының эчтәлеген сәхнәләштерү, бер-берсенә охшарга тырышмыйча хәрәкәт итә белү.

## 5.3. Музыка өлкәсендә төп бурычларны тормышка ашыруның эш формасы.

### 5.3.1.Бүлек “Тыңлау”

| Эш формасы | | | |
|---|---|---|---|
| Режим моменты | Педагогның бала белән бергә эшләве | Баланың мөстәкыйль эше | Гаилә белән бергә эшләү |
| Балаларны берләштерү формасы. | | | |
| Аерым<br>Төркем белән | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым | Аерым<br>Кечерәк төркем | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым |
| Музыканы куллану:<br>-иртәнге гимнастикада һәм физкультура шөгыльләрендә;<br>-музыка | 1.Шөгыльләр.<br>2.Бәйрәмнәр һәм күңел ачулар.<br>3.музыка көндәлек тормышта:<br>-башка шөгыльләрдә<br>-төркемнәрдә музыкаль | Музыка эшчәнлеге белән аерым шөгыльләнү өчен төркемнәрдә музыка почмагы булдыру: музыкаль инструментлар, уенчыклар, костюм элементлары, атрибутлар булдыру. Тавышлар белән экспереметлар үткәрү. | 1.Ата – аналар өчен белешмәлекләр булдыру.<br>2.Ата-аналар җыешларында катнашу.<br>3.Аерым әңгәмәләр үткәрү.<br>4.Ата – аналар белән берлектә бәйрәмнәр, бәйгеләр, күңел ачу |

| | | | |
|---|---|---|---|
| шөгыльләрендә;<br>-башка шөгыльләрдә;(тирә-якны танып белү, сөйләм телен үстерү, рәсем);<br>-җылы көннәрне урамда;<br>-сюжетлы-рольле уеннарда;<br>-көндезге йокы алдыннан;<br>-йокыдан уянганда;<br>-бәйрәмнәр һәм күңел ачу кичәләрендә. | әсәрләр тыңлау<br>-ял вакытында (өйрәнгән җырларны кабатлау)<br>-балалар уеннары<br>-рәсемнәр, балалар китапларыннан иллюстрацияләр карау.<br>-композиторлар портретларын карау. | 3. Үзлекләреннән уен формасында “бәйрәмнәр”, “концертлар” куюю.<br>4. Оркестрлар төзеп уйнау | кичәләре үткәрү, аларга әзерләнү.<br>5. Театральләштерелгән кичәләр, тавышлы оркестрлар оештыру.<br>6. Ачык ишекләр көне үткәрү.<br>7.Ата – аналар өчен ширмалар булдыру.<br>8.Гаиләдә бәйрәмнәр үткәрүгә ярдәм итү.<br>9. Театрлар, концертлар карау. |

**5.3.2.Бүлек “Җырлау”**

| Эш формасы | | | |
|---|---|---|---|
| Режим моменты | Педагогның бала белән бергә эшләве | Баланың мөстәкыйль эше | Гаилә белән бергә эшләү |
| Балаларны берләштерү формасы | | | |

| Аерым<br>Төркем белән | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым | Аерым<br>Төркем белән | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым |
|---|---|---|---|
| Җырны куллану:<br>-музыка шөгыльләрендә;<br>-юыну вакытларында;<br>-башка төр шөгыльләрдә;<br>-җылы көннәрне урамда;<br>-сюжетлы – рольле уеннарда;<br>-театральләшкән бәйрәмнәрдә;<br>-бәйрәмнәр һәм күңел ачу кичәләрендә. | 1.Шөгыльләр.<br>2.Бәйрәмнәр һәм күңел ачулар.<br>3.Музыка көндәлек тормышта:<br>-башка шөгыльләрдә;<br>-төркемнәрдә;<br>-ял вакытында (өйрәнгән җырларны кабатлау);<br>-уеннар, түгәрәк уеннары вакытында;<br>-рәсемнәр, балалар китапларыннан иллюстрацияләр карау. | Музыка эшчәнлеге белән аерым шөгыльләнү өчен төркемнәрдә музыка почмагы булдыру:<br>-музыка уен кораллары,<br>-уенчыклар,<br>-костюм элементлары,<br>-атрибутлар булдыру.<br>Тавышлар белән эксперементлар үткәрү.<br>3.Дидактик уеннар.<br>4. курчаклар өчен “концерт” әзерләү (курчаклар булып таныш җырларны җырлау) | 1.Ата – аналар өчен белешмәлекләр булдыру.<br>2.Ата – аналар җыелышләрында катнашу.<br>3.Аерым әңгәмәләр үткәрү.<br>4.Ата – аналар белән берлектә бәйрәмнәр, бәйгеләр, күңел ачу кичәләре үткәрү, аларга әзерләнү.<br>5.Театральләштерелгән кичәләр, тавышлы оркестрлар оештыру.<br>6. Ачык ишекләр көне үткәрү.<br>7. Ата – аналар өчен ширмалар булдыру.<br>8. Гаиләдә бәйрәмнәр үткәрүгә ярдәм итү.<br>9.Өйрәнгән җырларны өйдә әти – әниләр белән бергә җырлау. |

**3.3.Бүлек “Музыка ритмына хәрәкәтләр”**

| Эш формасы |
|---|

| Режим моменты | Педагогның бала белән бергә эшләве | Баланың мөстәкыйль эше | Гаилә белән бергә эшләү |
|---|---|---|---|
| Балаларны берләштерү формасы | | | |
| Аерым<br>Төркем белән | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым | Аерым<br>Төркем белән | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым |
| Музыка ритмына хәрәкәтләрне куллану:<br>-музыка шөгыльләрендә;<br>-иртәнге гимнастикада һәм физкультура шөгыльләрендә;<br>-башка төр шөгыльләрдә;<br>-сюжетлы – рольле уеннарда;<br>-теартальләшкән бәйрәмнәрдә;<br>-бәйрәмнәр һәм күңел ачу кичәләрендә. | 1.Шөгыльләр.<br>2.Бәйрәмнәр һәм күңел ачулар.<br>3.Музыка ритмына хәрәкәтләр көндәлек тормышта:<br>-башка шөгыльләрдә;<br>-төркемнәрдә;<br>-ял вакытында (өйрәнгән җырларны кабатлау);<br>-уеннар, түгәрәк уеннары вакытында;<br>-туган көн бәйрәмнәре. | Музыка эшчәнлеге белән аерым шөгыльләнү өчен төркемнәрдә музыка почмагы булдыру:<br>-музыка уен кораллары,<br> -уенчыклар,<br>-костюм элементлары,<br>-атрибутлар булдыру.<br>Тавышлар белән эксперементлар үткәрү.<br>2. Төрле бию көйләренә үзлекләреннән хәрәкәтләр уйлап табуга этәрү.<br>3.Курчаклар белән бәйрәм үткәрү, төрле хайваннар. Җәнлекләрне сурәтләгән хәрәкәтләр ясау. | 1.Ата – аналар өчен белешмәлекләр булдыру.<br>2.Ата – аналар җыелышләрында катнашу.<br>3.Аерым әңгәмәләр үткәрү.<br>4.Ата – аналар белән берлектә бәйрәмнәр, бәйгеләр, күңел ачу кичәләре үткәрү, аларга әзерләнү.<br>5.Театральләштерелгән кичәләр, тавышлы оркестрлар оештыру.<br>6. Ачык ишекләр көне үткәрү.<br>7. Ата – аналар өчен ширмалар булдыру.<br>8. Гаиләдә бәйрәмнәр үткәрүгә ярдәм итү.<br>9.Гаиләдә бию көйләренә фонотека булдыруга ярдәм итү. |

## VI. “Музыка” белем бирү өлкәсендә 6-7 яшьлек балаларга белем бирүнең психолого – педагогик эш эчтәлеге.

### 6.1. 6 яшьтән алып 7 яшькәчә балаларның яшь үзенчәлекләре.

Мәктәпкә хәзерлек төркеме балалары сюжетлы-рольле уеннарда кешеләр арасында барган катлаулы мөнәсәбәтләрне аңлый, тормыш вакыйгаларын чагылдыра башлыйлар (кызыл туй, бала туу, авыру, эшкә урнашу һ.б.). Уен эшчәнлеге катлаулана бара, олыларга ачылып бетмәгән билгеле бер мәгънә ала. Уен тирәлеге катлаулана, һәр кайсы үз сюжет сызыгы белән барган берничә үзәк барлыкка килә. Шул ук вакытта бала иптәшләренең уенын күзәтеп барырга һәм тоткан урынына карап үзенең торышын үзгәртә ала.(Бала сатучыга сатып алучы буларак кына түгел, ә әни сатып алучы яисә шофер сатып алучы буларак мөрәҗәгать итә). Ролне башкару шул роль эчендә генә түгел, ә бу ролнең уен тирәлегенең кай өлешендә башкарылуына да карый. (Автобус шоферы булып уйнаганда, бала пассажирлар өстеннән идарә итә. Шул ук вакытта ДПС инспекторына буйсына). Әгәр уен логикасы яңа роль кирәклеген ассызыкласа, бала элеккеге роле янына яңа роль вазыфасын да ала.

Тормыштан, укылган әсәрләрдән алынган образларны, рәсем сәнгатендә бала катлауландырып бирә. Рәсемнәр детальләшкән характер ала, төс гаммасы баетыла. Кызлар һәм малайлар ясаган рәсемнәр арасында аермалык төгәл күренә башлый.
Малайлар техниканы яратып ясасалар: космос, модельләр һ.б. Кызлар исә хатын – кыз образлары тудырырга яраталар: модельләр, балерина, принцесса, һ.б. Күп очракта көндәлек сюжетлар да очрый: әни белән кыз, бүлмә, һ.б. Кеше сурәте тагында пропорциональ һәм детальләшә бара: күзләр, кулда бармаклар, авыз, борын, каш, ияк барлыкка килә. Киемнәр төрле детальләр белән баетыла.

Мәктәпкә хәзерлек төркеме балалары төзелеш материалларыннан конструкцияләүне билгеле бер дәрәҗәдә үзләштергәннәр. Анализлауның гомумиләштерү ысуллары белән ирекле эш итәләр. Күз аллап ориенлаушу ярдәмендә ирекле төзелешләр симметрияле һәм пропорциональ булалар. Кирәкле материалны балалар дөрес һәм тиз сайлап алалар.

Төзелешнең эзлеклелеген һәм кирәкле материалны дөрес күзаллап, төрле катлаулыктагы эшне үзләре уйлап чыгарып та, схемага карап та эшлиләр. Кәгазь битен бөкләп төрле катлаулыктагы
эш башкаралар, өйрәткән очракта үзләре дә уйлап чыгарырга сәләтле. Бу эш төре балаларның пространстводагы күзаллауларын үстерер өчен кирәк. Табигый материаллар белән конструкцияләү катлаулана. Балалар инде бөтен композицияләр төзи, аларга кеше, җәнлек фигуралары кертә  алалар. Кабул итү сәләте үсә, ләкин бер үк вакытта берничә сыйфатны исәпкә ала алмыйлар. Образлы фикерләү сәләте үсә. Гомумиләштерү һәм фикерләү сәләте үсә.

Күз аллау сәләте үсә, ләкин өлкән төркем белән чагыштырганда ул кими. Бу төрле басым ясаулар белән бәйле, шул чиратта төрле мәглүмәт чаралары да. Игътибарлыклары үсүен дәвам итә,  ул иреклегә әйләнә. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләме үсә: аваз ягы, грамматик төзелеше, лексика. Бәйләнешле сөйләм үсеш ала. Сөйләмдә синонимнар, антонимнар, сыйфатлар кулланып сөйләшә башлый. Дөрес итеп оештырылган эшчәнлек нәтиҗәсендә диолог һәм монолог сөйләме үсә.

Мәктәпкәчә яшьтәге бала бакчаны тәмамлаганчы югары дәрәҗәдә танып белү, шәхескә якын килү сыйфатларына ия була, бу аңа киләчәктә мәктәптә яхшы укырга мөмкинлек бирәчәк.

## 6.2. 6-7 яшьлек балаларга музыка өлкәсендә күпкырлы белем бирү эшенең эчтәлеге.

Балаларны музыка сәнгате белән таныштыруны дәвам итү. Туган илнең музыкаль мирасы һәм заманча музыка белән кызыксыну хисе, аңлы мөнәсәбәт тәрбияләү. Төрле характердагы көйләр тыңлап, балалар күңелендә музыкаль хисләр уяту, музыкаль тәэсирләрен баетуны дәвам итү, музыкаль белемнәрен киңәйтү. Башлангыч музыкаль төшенчәләр белән таныштыру.

**“Тыңлау”.**

Авазларның югарылыгын (квинта-терция эчендә) аера белү күнекмәләрен үстерүне дәвам итү; тәэсирләрен баету, музыканы ишетү сәләтен формалаштыру, музыкаль хәтерләрен үстерү. Музыка әсәрләренә бәяләмә биргәндә, үзләренең уй – фикерләрен, хис тойгыларын ачык әйтш белү, хыял, зиһен, музыка ишетү сәләтләрен үстерү. Башлангыч музыка төшенчәләре белән таныштыру.

**“Җырлау”.**
Җырлау тавышын камилләштерү. Беренче октава “до” – икенче октава “ре” диапазонында сәнгатьле итеп җырлау күнекмәләрен ныгыту. Җырны мөстәкыйль рәвештә музыка уен коралына кушылып, музыка уен коралыннан башка ялгыз һәм күмәк башкару осталыгын ныгыту.

**“Музыка ритмына хәрәкәтләр”.**
Бию хәрәкәтләренең күнекмәләрен үстерү. Төрле характерлы музыкага ритмлы хәрәкәтләнеп, хәрәкәтләр аша бию эчтәлеген тасвирлап күрсәтә белү. Төрле халык биюләренең үзенчәлекләре белән таныштыру. Биюләрдә, сәхнәләштерелгән җырларда төрле образларны сәнгатьле итеп башкару күнекмәләрен формалаштыру.

**Ел ахырына бала:**
-тыңлаган әсәр кайсы жанрга туры килүен һәм нинди музыка уен коралында башкарылганын белү.
-музыкаль әсәрнең гомуми характерын һәм кисәкләренең характерын билгеләү, музыкаль тасвирлау чараларын: темп, динамика, тембрны аера белү; музыкаль әсәрләрнең интонацион – көйле үзенчәлекләрен белү.
-музыка сәнгатенә булган мөнәсәбәтләрен рәсемдә. Хәрәкәт аша чагылдыра белү.
-гади генә җырларны җайлы диапазонда, көен дөрес җырлап, сәнгатьле башкара белү.
-төп бию хәрәкәтләрен матур, дөрес башкару.
-уен җырларын сәхнәләштерү, түгәрәк һәм башка төр уеннарда образлы хәрәкәтләрнең төрле вариантларын уйлап таба белү.

## 6.3. Музыка өлкәсендә төп бурычларны тормышка ашыруның эш формасы.

### 6.3.1.Бүлек “Тыңлау”

| Эш формасы |
| --- |

| Режим моменты | Педагогның бала белән бергә эшләве | Баланың мөстәкыйль эше | Гаилә белән бергә эшләү |
|---|---|---|---|
| Балаларны берләштерү формасы. | | | |
| Аерым<br>Төркем белән | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым | Аерым<br>Кечерәк төркем | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым |
| Музыканы куллану:<br>-иртәнге гимнастикада һәм физкультура шөгыльләрендә;<br>-музыка шөгыльләрендә;<br>-башка шөгыльләрдә;(тирә-якны танып белү, сөйләм телен үстерү, рәсем);<br>-җылы көннәрне урамда;<br>-сюжетлы-рольле уеннарда;<br>-көндезге йокы | 1.Шөгыльләр.<br>2.Бәйрәмнәр һәм күңел ачулар.<br>3.музыка көндәлек тормышта:<br>-башка шөгыльләрдә<br>-төркемнәрдә музыкаль әсәрләр тыңлау<br>-ял вакытында (өйрәнгән җырларны кабатлау)<br>-балалар уеннары<br>-рәсемнәр, балалар китапларыннан иллюстрацияләр карау.<br>-композиторлар портретларын карау. | Музыка эшчәнлеге белән аерым шөгыльләнү өчен төркемнәрдә музыка почмагы булдыру: музыкаль инструментлар, уенчыклар, костюм элементлары, атрибутлар булдыру. Тавышлар белән эксперементлар үткәрү.<br>3. Үзлекләреннән уен формасында “бәйрәмнәр”, “концертлар” кую.<br>4. Оркестрлар төзеп уйнау | 1.Ата – аналар өчен белешмәлекләр булдыру.<br>2.Ата-аналар җыешларында катнашу.<br>3.Аерым әңгәмәләр үткәрү.<br>4.Ата – аналар белән берлектә бәйрәмнәр, бәйгеләр, күңел ачу кичәләре үткәрү, аларга әзерләнү.<br>5. Театральләштерелгән кичәләр, тавышлы оркестрлар оештыру.<br>6. Ачык ишекләр көне үткәрү.<br>7.Ата – аналар өчен ширмалар булдыру.<br>8.Гаиләдә бәйрәмнәр үткәрүгә ярдәм итү.<br>9. Театрлар, концертлар карау. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| алдыннан;<br>-йокыдан уянганда;<br>-бәйрәмнәр һәм күңел ачу кичәләрендә. | | | |

**6.3.2.Бүлек “Җырлау”**

| Эш формасы | | | |
|---|---|---|---|
| Режим моменты | Педагогның бала белән бергә эшләве | Баланың мөстәкыйль эше | Гаилә белән бергә эшләү |
| Балаларны берләштерү формасы | | | |
| Аерым<br>Төркем белән | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым | Аерым<br>Төркем белән | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым |
| Җырны куллану:<br>-музыка шөгыльләрендә;<br>-юыну вакытларында;<br>-башка төр шөгыльләрдә;<br>-җылы көннәрне урамда; | 1.Шөгыльләр.<br>2.Бәйрәмнәр һәм күңел ачулар.<br>3.Музыка көндәлек тормышта:<br>-башка шөгыльләрдә;<br>-төркемнәрдә;<br>-ял вакытында | Музыка эшчәнлеге белән аерым шөгыльләнү өчен төркемнәрдә музыка почмагы булдыру:<br>-музыка уен кораллары,<br>-уенчыклар,<br>-костюм элементлары,<br>-атрибутлар булдыру. | 1.Ата – аналар өчен белешмәлекләр булдыру.<br>2.Ата – аналар җыелышларында катнашу.<br>3.Аерым әңгәмәләр үткәрү.<br>4.Ата – аналар белән берлектә бәйрәмнәр, бәйгеләр, күңел ачу кичәләре үткәрү, аларга әзерләнү.<br>5.Театральләштерелгән кичәләр, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| -сюжетлы – рольле уеннарда;<br>-театральләшкән бәйрәмнәрдә;<br>-бәйрәмнәр һәм күңел ачу кичәләрендә. | (өйрәнгән жырларны кабатлау);<br>-уеннар, түгәрәк уеннары вакытында;<br>-рәсемнәр, балалар китапларыннан иллюстрацияләр карау. | Тавышлар белән эксперементлар үткәрү.<br>3.Дидактик уеннар.<br>4. курчаклар өчен “концерт” әзерләү (курчаклар булып таныш жырларны жырлау) | тавышлы оркестрлар оештыру.<br>6. Ачык ишекләр көне үткәрү.<br>7. Ата – аналар өчен ширмалар булдыру.<br>8. Гаиләдә бәйрәмнәр үткәрүгә ярдәм итү.<br>9.Өйрәнгән жырларны өйдә әти – әниләр белән бергә жырлау. |

**63.3.Бүлек “Музыка ритмына хәрәкәтләр”**

| Эш формасы | | | |
|---|---|---|---|
| Режим моменты | Педагогның бала белән бергә эшләве | Баланың мөстәкыйль эше | Гаилә белән бергә эшләү |
| Балаларны берләштерү формасы | | | |
| Аерым<br>Төркем белән | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым | Аерым<br>Төркем белән | Төркем белән<br>Кечерәк төркем<br>Аерым |
| Музыка ритмына хәрәкәтләрне куллану:<br>-музыка | 1.Шөгыльләр.<br>2.Бәйрәмнәр һәм күңел ачулар.<br>3.Музыка ритмына | Музыка эшчәнлеге белән аерым шөгыльләнү өчен төркемнәрдә музыка | 1.Ата – аналар өчен белешмәлекләр булдыру.<br>2.Ата – аналар жыелышләрында катнашу. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| шөгыльләрендә;<br>-иртәнге гимнастикада һәм физкультура шөгыльләрендә;<br>-башка төр шөгыльләрдә;<br>-сюжетлы – рольле уеннарда;<br>-теартальләшкән бәйрәмнәрдә;<br>-бәйрәмнәр һәм күңел ачу кичәләрендә. | хәрәкәтләр көндәлек тормышта:<br>-башка шөгыльләрдә;<br>-төркемнәрдә;<br>-ял вакытында (өйрәнгән җырларны кабатлау);<br>-уеннар, түгәрәк уеннары вакытында;<br>-туган көн бәйрәмнәре. | почмагы булдыру:<br>-музыка уен кораллары,<br>-уенчыклар,<br>-костюм элементлары,<br>-атрибутлар булдыру.<br>Тавышлар белән эксперементлар үткәрү.<br>2. Төрле бию көйләренә үзлекләреннән хәрәкәтләр уйлап табуга этәрү.<br>3.Курчаклар белән бәйрәм үткәрү, төрле хайваннар.<br>Җәнлекләрне сурәтләгән хәрәкәтләр ясау. | 3.Аерым әңгәмәләр үткәрү.<br>4.Ата – аналар белән берлектә бәйрәмнәр, бәйгеләр, күңел ачу кичәләре үткәрү, аларга әзерләнү.<br>5.Театральләштерелгән кичәләр, тавышлы оркестрлар оештыру.<br>6. Ачык ишекләр көне үткәрү.<br>7. Ата – аналар өчен ширмалар булдыру.<br>8. Гаиләдә бәйрәмнәр үткәрүгә ярдәм итү.<br>9.Гаиләдә бию көйләренә фонотека булдыруга ярдәм итү. |

**7.1. Кечкенәләр төркемендә “Музыка” оештырылган белем бирү эшчәнлегенең киңәйтелгән комплекслы - тематик планы**

**СЕНТЯБРЬ. Тема :”Мин һәм балалар бакчасы” Кечкенәләр төркеме**.

| Тыңлау. | Җырлау өчен | Максат | Ритмик хәрәкәтләр. | Биюләр Уеннар | Кайчан Үтә. |
|---|---|---|---|---|---|
| “Марш” | “Бишек | Музыканы башыннан алып ахырына | -Төрле характерда | | 3 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| И.Шәмсетдинов муз; | җыры"(т.х.к.) | кадәр игьтибар белән тыңлый белү күнекмәләре тәрбияләү.Б-ны тигез яңгыраешлы итеп җырларга; Төгәл ритмик, күтәренке күңел б\н атлап йөрү. | йөрү; Маршка кулларны селтәп йөрергә күнектерү. | | |
| "Марш" И.Шәмсетдинов муз; | "Бишек җыры"(т.х.к.) | Музыканы тыңларга өйрәтү.Музыка дөньясының гүзәллеген аңлый белергә өйрәтү. | "Яфраклар б\н күнегү. | | 5 |
| Әпипә"т.х.Кю.Виноградов эшкәртүендә | "Яфрак бәйрәме"Л. Лерон сүз, Р.Еникеева муз; | Музыканың төрен аерырга өйрәтү.Кычкырмыйча табигый б\н җырларга өйрәтү.Тигез матур хәрәкәтләр башкару. | "Яфраклар б\н күнегү" Е .Тиличева. | "Куш кулым"!(т.х.җырлы биюле уен.) | 10 |
| Әпипә"т.х.Кю.Виноградов эшкәртүендә | "Яфрак бәйрәме" Л. Лерон сүз, Р.Еникеевамуз; | Музыкаль әсәрне дикъкать б\н тыңларга, характерын билгеләргә өйрәтү.Кычкырмыйча табигый тавыш б\н җырларга өйрәтү.Бию хәрәкәтләренең күнекмәләрен үстерү. | "Чәбәкәй" Р.Ахиярова муз Х.Халиков сүз; | "Эх,Зилем – Зиләле!"(т.х.җырлы уены) | 12 |
| "Көз" Р.Еникеева муз. | "Кояшкай"(т.х.к) | Музыкага эмоциональ мөнәсәбәт тәрбияләү.Сәнгатье, ачык тавыш б\н җырлау күнекмәләрен үстерү.Бию хәрәкәтләренең күнекмәләрен үстерү. | "Йөрибез" Ф.Шәймарданова муз; | "Күңелле карусель"т.хҗырлы уены. | 17 |
| "Көз Р.Еникеева муз; | "Кояшкай"(т.х.к.) | Музыкаль әсәрне дикатъ б\н тыңларга, характерын билгеләргә өйрәтү. Хәрәкәтләрне тигез, матур итеп башкаруны ныгыту. | "Күңелле" А.Монасыйпов муз; | "Куш кулым"(т.х.җырлы уены.) | 19 |
| "Бишек җыры" Г.Тукайсүз; | "Гөмбәләр бию" Г.Гилажетдинова сүз; | Музыканы ишетү сәлатен үстерү, Тигез, ачык тавыш б\н җырлау күнекмәләре бирү.Бию хәрәкәтләренең күнекмәләрен | "Яфраклар б\н күнегү" Е.Тиличева. | "Зәңгәр чәчәк"!т.х.җ. уен. | 24 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | үстерү. | | | |
| "Туган авыл"Г.Тукай сүз.; | "Гөмбәләр биюе" Г..Гилаҗетдинова сүз; | Балалрны тигез яңгыраешлы итеп җырларга; музыкаль әсәрнең характерын билгеләргә өйрәтү.өгәл ритмик, күтәренке күңел б \н атлап йөрү. | "Чәбәкәй"Р.Ахиярова муз Х.Халиков сүз Яфраклар б\н бию"Т.Вафинамуз; | "Кайда минем балалар" Н.Г. Кононов. | 26 |

Октябрь. Тема "Көз җитте" Кечкенәләр төркеме

| Тыңлау. | Җырлау өчен. | Максат. | Ритмик хәрәкәтләр. | Биюләр. Уеннар. | Кайчан үтә. |
|---|---|---|---|---|---|
